ҖОМГА
19
ФЕВРАЛЬ
1943 ел.
№ 41 (6763)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

ГРАФИК—ТРАНСПОРТНЫҢ ТИМЕР ЗАКОНЫ

Казан тимер юлы—Москваны Урал белән тоташтыра торган иң мөһим магистральләрнең берсе. Ул хаклы рәвештә «Кызыл Армиянең арсеналы» дип атала. Казан тимер юлчылары фронт өчен һәм оборона промышленносте өчен йөк ташу буенча дәүләт тарафыннан бирелгән мөһим заданиеләрне үтиләр. Бу хәл, бөтен эштә, беренче чиратта, поездлар хәрәкәте графигын үтәүдә коллективның җаваплылыгын бик нык күтәрә.

График — универсаль үлчәү транспорт өчен тимер закон. Ватан сугышы шартларында аны бозу — ил алдында җинаять ул. Аны төгәл үтәү — зур патриотик эш, һөҗүм итеп баручы Кызыл Армиягә эффектлы ярдәм.

Красноуфимск бүлеге диспетчеры иптәш Вальнев, икенче хәрби кыш шартларында поездларны төгәл график буенча төгәл хәрәкәт иттерүнең әһәмиятен бик яхшы аңлаган хәлдә юлда беренче буларак, илнең атаклы диспетчеры иптәш Еремкинның методын кулланды. Иптәш Вальнев, Еремин белән ярышып, хәрәкәт графигын, поездларны каршылау һәм озату нормасын уңышлы үтәп бара. Поездлар хәрәкәтен тизләтү өчен көрәшне оештыручы иптәш Вальнев паровозчыларның, вагончыларның, хәрәкәтчеләрнең һәм башкаларның бердәм эшләүләрен тәэмин итә.

Яшь диспетчерның гүзәл үрнәге башка хәрәкәт командирларын да үзенә тарта. Әгерҗе бүлегендә диспетчер Прудников, Юдинода Федянин, Сергачта Турчановалар иптәш Еремин методын уңышлы кулланалар.

Әгәр дә юл җитәкчелеге Еремин методын куллану өчен көрәштән читтә тормаса, ереминчылар саны тагын да күп булыр иде. Кызганычка каршы, юл начальнигы иптәш Сорокин һәм политбүлек начальнигы иптәш Григорьев Казан тимер юлында Еремин методын җәелдерү өлкәсендә бик аз эшлиләр әле. Диспетчерлар арасында ярыш формаль төстә генә бара яки бөтенләй алып барылмый, кыйммәтле тәҗрибә артта калучыларга күчерелми.

Әгерҗе бүлеге начальнигы иптәш Степанов һәм политбүлек начальнигы иптәш Плоткин бу юнәлештә аеруча начар эшлиләр. Алар поездлар хәрәкәтен оештыруның практикада сыналган иң яхшы юлын—Еремин методын куллануны оештырмыйлар график өчен көрәшне үз агымына куялар. Шуның нәтиҗәсе буларак, Әгерҗе бүлеге графикны системалы рәвештә үтәми.

Бүлек җитәкчелеге графикны үтәүдә кыенлыкларны алдан күрә белми, бүлек эшендәге маневрлыкны арттыру өчен житди көрәш алып бармый; участокларның поездлар җибәрү сәләтен арттыруның резервлары начар файдаланыла һәм шуның аркасында поездлар хәрәкәтенә еш кына тоткарлыклар ясала.

График еш кына Әгерҗе депосы (начальнигы иптәш Лисовский) паровозчылары һәм шундагы ягулык складлары работниклары гаебе буенча бозыла. Ләкин командирлар моннан тиешле нәтиҗә ясамыйлар, житешсезлекләрне бетерү чарасын күрмиләр.

Дөрес, күптән түгел генә анда паровозчылар һәм диспетчерлар арасында Вятские Поляны һәм Әгерҗе участогында су алу өчен юлда туктамыйча поездлар йөртү буенча гүзәл хәрәкәт башланып китте. Бу сизелерлек эффект биргән иде, ләкин ул да тиешенчә җәелдерелми әле.

Шундый ук хәлне без Юдино бүлегендә дә (бүлек начальнигы Кротов, политбүлек начальнигы Иванов) күрәбез. Анда графикны төгәл үтәү турында күп сөйлиләр, ләкин аның өчен көрәшне җитәрлек дәрәҗәдә алып бармыйлар.

Графикны үтәүдә Төрләмә һәм Урмар станцияләрендәге ягулык складларының начар эшләүләре дә шактый комачаулый. Ләкин бу хәл бүлек җитәкчеләрен артык борчымый.

Иптәш Сталин үзенең чыгышларыннан берсендә болай дигән иде: «Тимер юл транспортының хәлиткеч һәм бөтен нәрсәне эченә ала торган ролен тормышка ашыру өчен барыннан да элек, аның барлык частьларының бердәм булуы һәм ачык билгеләнгән тәртиптә эшләүләре таләп ителә. Транспортта дисциплина дип аталган нәрсә, нәкъ әнә шул инде». Бөек юлбашчыбызның һәм полководецыбызның бу күрсәтмәсе Казан тимер юлчыларының бөтен эшенә нигез булып салынырга тиеш. Ватанның, халыкның, фронтның таләбе шундый.



Шушы елның 4 нче февралендә иптәш М. И. Калинин Советлар Союзы Маршалы Г. К. Жуковка, Авиация генерал-полкогнигы А. А. Новиковка һәм авиация генерал-лейтенанты А. Е. Головановка Беренче дәрәҗә Суворов ордены тапшырды. Иптәш Жуковка шулай ук Маршалның аерымлык билгесе—«Маршал йолдызы» тапшырылды. Рәсемдә: иптәш М. И. Калинин бүләкләнүчеләргә орденнар тапшырганнан соң алар белән беседа ясый. Сулдан уңга: Жуков, Новиков һәм Голованов иптәшләр.

Ф. Кислов фотосы. (ТАСС фотохроникасы).

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

18 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

18 нче февральгә каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

Ворошиловградтан көньяктарак һәм көньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Н-че гвардия часте дошманга каршы сугышларда немецларның 20 танкысын, 2 бронемашинасын юк итте һәм 600 гә якын немец солдатларын һәм офицерларын кырып ташлады. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды.

* * *

Краматорская районында безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар. Немецлар Н-че подразделениегә каршы контратакага бик күп пехота һәм 17 танк җибәрделәр. Безнең сугышчылар гитлерчыларның контратакасын кире кайтардылар, дошманның 2 танкысын яндырдылар һәм 200 дән артык немец солдатларын һәм офицерларын кырдылар. Икенче бер участокта безнең частьлар, кинәт удар ясап, немецларны халык яши торган бер пункттан бәреп чыгардылар, 4 орудие һәм 7 миномет кулга төшерделәр. 120 дошман солдаты һәм офицеры плен алынды.

* * *

Харьковтан ерак түгел генә безнең танкистлар, бер тимер юл станциясен алганнан соң, дошманның 150 паровозын, йөкләр төялгән 14 тимер юл эшелонын, шул исәптән снарядлар һәм авиабомбалар төялгән 75 вагонын, 4 авыр танкысын һәм башка трофейлар кулга төшерделәр.

* * *

Змиев районында безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Халык яши торган бер пункт өчен булган сугышта Н-че часть подразделениеләре немецларның бер батальон пехотасын тар-мар иттеләр, бер бронемашина, 2 самоход орудие, танкка каршы ата торган 7 мылтык, 15 пулемет һәм башка трофейлар кулга төшерделәр.

* * *

Курскидан төньяктарак безнең частьлар сугыша-сугыша алга бардылар. Совет танкистлары халык яши торган бер пунктка бәреп керделәр һәм дошман гарнизонын тар-мар иттеләр. 100 дән артык немец солдатлары һәм офицерлары кырып ташланды, дошманның 5 орудиесе һәм 13 автомашинасы юк ителде. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды.

* * *

Украинада бер районда хәрәкәт итүче партизаннар отряды 3 нче февральдән 8 енә кадәр дошман гарнизоннарына кинәт һөҗүмнәр ясаган һәм 400 гә якын немец-фашист басып алучыларны кырып ташлаган. Совет патриотлары 3 пулемет, 210 винтовка, 15 пистолет һәм берничә азык склады кулга төшергәннәр. Партизаннар крестьяннардан гитлерчылар талап алган бик күп ашлыкны халыкка өләшеп биргәннәр. Берничә йөз эшче һәм колхозчы азат ителгән. Аларны немецлар ирексезләп Германиягә каторга эшләренә алып китмәкче булганнар.

* * *

Краснодарда кулга төшерелгән немецлар почтасында немец солдатларының һәм офицерларының күп хатлары табылды. Обер-ефрейтор Маттиас Янсен болай дип яза: «...Мондый күңелсез яңа елны мин беркайчан да каршылаганым юк иде. Ул кичне без чигендек. Чигенү безнең өчен җиңел булмады. Минем күп иптәшләрем инде яңа елны беркайчан да каршыламаячаклар. Без барыбыз да солдат кыяфәтен югалттык, чөнки соңгы көннәр коточкыч иде...» Солдат Зигфрид Биркман үзенең туганы Эвальдка болай дип яза: «Без Кавказдан чигенүебездә дәвам итәбез һәм 340 километр киттек инде. Ни өчен шулай булып чыккандыр—беркем дә белми. Кайбер солдатларның әйтүенчә, чигенү ниндидер югары фикерләр нәтиҗәсендә килеп чыккан. Миңа исә бер генә фикер мәгълүм—мин кечкенә кеше һәм барын да белергә тиеш түгел. Мин монда руслар икенче Сталинград казаны ясарга телиләрдер дип уйлыйм».

* * *

Немец-фашист кабахәтләр Краснодар краендагы Куржинский хуторын бөтенләй җимергәннәр. Чигенер алдыннан немец офицеры бөтен халыкны җыеп, аларга, ату белән куркытып, ярты сәгать эчендә хуторны бушатырга приказ биргән. Кешеләр барысы да үзләренең балаларын һәм кирәкле әйберләрен алу өчен өйләренә ташланганнар. Гитлерчылар шунда ук автоматлардан ут ачканнар һәм йортларны яндыра башлаганнар. Күп кешеләр үлгән һәм яраланган. Гитлерчылар хуторның исән калган кешеләрен тылга куып алып киткәннәр. Немецларның чигенү юлларын кискән Кызыл Армия частьлары совет гражданнарын фашистлар коллыгыннан азат иттеләр.

СССР Верховный Советы Президиумы УКАЗЫ

СССР ның Хәрби-диңгез флотының личный составы өчен яңа аерымлык билгеләре кертү турында

1. Хәрби Диңгез Флоты Халык Комиссариатының үтенечен канәгатьләндерергә һәм СССР ның Хәрби Диңгез Флотының личный составы өчен хәзерге аерымлык билгеләре урынына яңа билгеләр—погоннар кертергә.

2. Хәрби Диңгез Флотының личный составының яңа аерымлык билгеләренең үрнәкләрен һәм язма аңлатмасын расларга.

3. Кызыл Армиядә кертелгән аерымлык билгеләрен Хәрби Диңгез Флотының үзләре өчен гомуми армия формасы кием билгеләнгән частьларындагы личный составка да кулланырга.

4. СССР Хәрби Диңгез Флоты Халык Комиссарына,—яңа аерымлык билгеләренә күчү срокларын билгеләргә һәм Хәрби Диңгез Флотының личный составының кием формасына тиешле үзгәрешләрне кертергә.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. Калинин.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. Горкин.

Москва, Кремль. 15 февраль.

ХӘРБИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРНЕҢ СЕМЬЯЛАРЫНА ЯРДӘМ

Казан Авыл хуҗалыгы институты дирекциясе, партия һәм профсоюз оешмалары Кызыл Армия сугышчыларының һәм командирларының семьяларына ярдәм итү эшендә зур активлык күрсәтәләр.

Институтта эшләгән хәрби хезмәткәрләрнең семьяларына 1942 нче елда 67.000 килограмм азык продуктлары, шул исәптән 6.400 килограмм бәрәңге, 11.000 килограммнан артык кәбестә, 120 килограмм бал һәм башка авыл хуҗалыгы продуктлары бирелде, 240 кубометр утын китерелде.

Соңгы вакытта хәрби хезмәткәрләрнең семья членнарының көн-күреш якларын тикшерү эшләре алып барыла. Мохтаҗ булганнарга азык һәм промышленность товарлары белән ярдәм күрсәтелә.

Барлык авыл яшьләренә, колхоз, совхоз һәм МТС комсомолецларына һәм комсомолкаларына

МОСКВА ӨЛКӘСЕ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫНЫҢ АЛДЫНГЫ ЯШЬЛӘРЕННӘН ХАТ

Кадерле иптәшләр!

Героик Кызыл Армия җиңбатышка таба уңышлы рәвештә алга бара, совет җирен кабахәт немец басып алучылардан чистарта. Шәһәрләр һәм авыллар бер-бер артлы совет семьясына кайтарылалар, алар өстендә җиңүле кызыл байрак яңадан җилферди.

Совет сугышчыларының батырлыгы һәм геройлыгы сезне фронтка ярдәмегезне ике өлеш, өч өлеш арттырырга, илгә һәм Кызыл Армиягә тагын да күбрәк икмәк, бәрәңге, ит, техник культуралар бирергә чакыра. Хезмәттә—сугыштагы кебек. Безнең яшьләрнең лозунгысы шул. Фронтовикларга охшарга. Колхоз авылының яшь патриотлары шул фикер белән яшиләр.

Үткән авыл хуҗалыгы елында Москва өлкәсенең авыл яшьләре колхоз һәм совхоз кырларында тырышып эшләделәр. Колхозларда һәм совхозлара 165 мең яшь колхозчы ирләр һәм кызлар, 110.000 пионерлар һәм мәктәп балалары эшләде. Фронтка киткән тракторчылар урынында 3.000 нән артык кызлар трактор йөрттеләр.

Яшьләр тракторларга һәм башка авыл хуҗалыгы машиналарына 2 миллион сумлыктан артык запас частьлар һәм инструментлар җыйдылар. Комсомолецлар һәм яшьләр «Москва колхозчысы» исемле танклар колоннасы төзелешенә үзләренең саклык акчаларыннан 25 миллион сум керттеләр.

Билгеле, безнең яшьләр һәрбер колхозда, совхозда һәм МТС та яхшы эшләделәр, дип әйтеп булмый. Ялкауланырга, эштән баш тартырга теләүче, аңсыз яшь колхозчылар да булды. Ягулыкны артык күп тоткан, урып-җыюда игеннәрне күп югалткан тракторчылар һәм комбайнчылар булды. Кайбер колхозларда һәм совхозларда яшьләр, бигрәк тә бәрәңге буенча, югары уңыш алу өчен көрәшне йомшак алып бардылар.

Быел бу кимчелекләргә юл куярга ярамый.

Һәрбер колхозда, совхозда һәм МТС та яшьләр, комсомолецлар җитәкчелегендә, язгы чәчү кампаниясенә уңышлы рәвештә әзерләнүне һәм үткәрүне сугышчан тестә оештыручылар булып чыгарга тиешләр.

Яшь колхозчы ирләр һәм хатын-кызлар, совхоз һәм МТС эшчеләре!

Безнең илебез сугыш вакытындагы икенче яз алдында тора. Иген уңышының нигезе чәчү вакытында салына. Халык мәкале «Ни чәчсәң, шуны урырсың» ди.

Безнең беренче һәм төп бурычыбыз—иген уңышын арттыру, ашлыкны, бәрәңгене, яшелчәне күбрәк җыеп алу. Алар безнең илебезгә самолет, танк, пушка һәм сугыш припаслары шикелле үк кирәк. Икмәк, яшелчә һәм бәрәңге өчен көрәш—ул, немецларны җиңү өчен көрәш дигән сүз. Шуңа күрә дә безнең бурычыбыз—һәрбер колхоз, совхоз югары уңыш алырлык итеп эшләү.

Һәрбер машинадан тулысынча файдаланырга, тракторларның эшсез торуларына, ягулыкны һәм майлау материалларын тиешсезгә тотуга юл куймаска кирәк.

Яшьләр чәчүне үткәрү өчен урындагы барлык запаслардан һәм мөмкинлекләрдән файдалану эшенә керешергә тиешләр.

Язгы чәчүгә үрнәк булырлык итеп әзерләнергә, аны вакытында һәм югары сыйфатлы итеп үткәрергә. Хәзер бу безнең иң әһәмиятле патриотлык эшебез.

Без үзебезнең киңәшмәбездә үзара киңәшкәннән соң, түбәндәгеләрне үткәрергә карар бирдек:

КЫШКЫ АГРОТЕХНИКА ЧАРАЛАРЫ ҮТКӘРҮ БУЕНЧА

1. Яшьләр һәм барлык колхозчылар арасында агротехниканы массовый тестә өйрәнүне киң күләмдә оештырырга.

Язгы чәчү башланганчыга кадәр комсомолецлар һәм яшь колхозчылар тиресне саклау һәм куллану кагыйдәләрен, чәчүлек орлыкларга карата нинди таләпләр куелуны, чәчүне ничек итеп дөрес үткәрүне, яз көне җирне ничек эшкәртүне һәм ни өчен тирән сөрергә кирәклекне, хезмәтнең ничек оештырылырга һәм ничек итеп учетка алынырга тиешлеген, иген уңышын арттырган өчен өстәмә түләү тәртибен, бәрәңгедән ничек итеп югары уңыш алырга кирәклекне өйрәнергә тиешләр.

2. Чана юлы өзелгәнчегә кадәр колхозлардагы ишек алларыннан, шулай ук колхозчыларның ишек алларыннан бөтен тиресне басуга чыгарырга, аның яхшы итеп салынган һәм тапталган хәлдә саклануына ирешергә.

Җирле ашламалар җыюны һәм әзерләүне көчәйтергә, бу эшкә пионерларны һәм мәктәп балаларын тартырга. Көл һәм тавык тизәге җыярга, аны сакларга һәм басуга чыгарырга, компостлар, торф һәм башка җирле ашламалар әзерләнүе оештырырга.

3. Комсомолецлардан һәм яшьләрдән югары иген уңышы звенолары төзергә. Бу звенолар үз участокларын хәзер үк җентекләп әзерләргә, күбрәк ашламалар җыярга һәм басуга чыгарырга, чәчүлек орлыкларны яхшы итеп әзерләргә, ат инвентарен тулысынча тәртипкә кертергә һәм кул белән эшли торган бөтен инвентарьны әзерләргә тиешләр.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ӘЗЕРЛЕК ҺӘМ АНЫ ҮТКӘРҮ ЧОРЫНДАГЫ МАССОВЫЙ-ПОЛИТИК ЭШ ТУРЫНДА

1. Һәрбер кырчылык бригадасына иң яхшы комсомолецлардан һәм яшьләрдән агитаторлар билгеләргә, аларга колхозчылар белән һәрвакыт бәседалар үткәрүне, Совет Информбюросы белдерүләрен, газета мәкаләләрен укуны һәм аңлатуны тапшырырга. Газеталарның турыдан-туры басуга, бригадага вакытында җиткерелүенә ирешергә.

2. Колхозларда һәм совхозларда чәчүгә әзерлекнең һәм аны үткәрүнең барышын газеталар аркылы, сугышчан листоклар аркылы, күрсәткечләр такталары аркылы киң күләмдә яктыртырга. Алынган йөкләмәләрнең үтәлүен тикшерергә, тикшерүнең нәтиҗәләре турында җыелышларда, производство киңәшмәләрендә, агитаторлар беседаларында сөйләргә, алдынгыларны кызыксындырырга һәм ялкауларны тәнкыйть итәргә.

3. Яшьләр арасында культура-масса эшен кискен төстә яхшыртырга, художество үзэшчәнлеге, бию һәм җыр кичәләре оештырырга.

4. Чәчүгә әзерлек барышында һәм чәчү вакытында системалы рәвештә, мәсәлән, 10 көнтә бер тапкыр, яшьләрне җыярга, аларга чәчүгә әзерлек буенча нәрсәләр эшләнгәнлекне, чәчүнең ничек баруын сөйләргә һәм эшне яхшырту өчен тагын нәрсәләр эшләргә кирәклек турында алар белән киңәшергә.

МАШИНАЛАРНЫ ҺӘМ ИНВЕНТАРЬНЫ КЫР ЭШЛӘРЕНӘ ӘЗЕРЛӘҮ БУЕНЧА

1. Һәрбер тракторның, сабанның, тырманың, чәчү машинасының ничек төзәтелгәнлеген 1 нче апрельгә кадәр тикшереп чыгарга. Әгәр колхозда сабан җитмәсә—аны табарга; тырманың тешләре тулы булмаса—куярга, тирән үтмәсләнгән булса—кайрарга. Без һәрбер кырчылык бригадасында җитәрлек кадәр санда төзек инвентарь булуга ирешергә телибез.

2. Колхоз алачыкларының эшен юлга салырга: агач күмере әзерләргә, тимер ватыклары җыярга, җитмәгән инструментларны эзләп табарга. Алачык булмаган колхозларда комсомолецларны, комсомолкаларны яки яшь колхозчыларны күрше колхозлардагы алачыкларга эшкә өйрәнү өчен җибәрергә.

3. Үткән елгы тәҗрибә буенча тракторларга һәм башка авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясау өчен запас частьлар һәм инструментлар җыярга һәм әзерләргә. Бу эшне 1 нче апрельгә кадәр тәмам итәргә.

4. МТС комсомолецлары, колхозлардагы комсомолецлар һәм яшьләр белән бергәләп, февраль аенда МТС мастерскойларында һәм усадьбаларында үрнәк булырлык тәртип урнаштырырга, тракторларны һәм авыл хуҗалыгы машиналарын саклау өчен өсте ябулы лапаслар төзүдә актив катнашырга тиешләр.

ОРЛЫКЛАРНЫ ЧӘЧҮГӘ ӘЗЕРЛӘҮ БУЕНЧА

1. Колхозларда бөтен чәчү мәйданына кирәкле орлыкларның тулысынча әзерләнүенә ирешергә. Моның өчен, барыннан да элек, колхозларда күпме орлык барлыкны һәм күпме орлык кирәклекне белергә. Әгәр орлык җитешмәсә, җитмәгән өлешен каян табарга мөмкин икәнлекне белергә, колхозчыларның үз запасларыннан җыюга керешергә, башка колхозларның иптәшләрчә ярдәмен оештырырга.

Орлыкларның саклануына көндәлек ныклы контроль куюны тәэмин итәргә, аларның урланмавын һәм бозылмавын күзәтеп торырга.

2. Чәчү материалының югары сыйфатлы булуы өчен барлык чараларны күрергә: барлык орлыкларны сортларга аерырга, аларның чисталыгын, тишелеп чыгуын тикшерергә, начар орлыкларны яхшы орлыкка алыштырырга.

Чәчү алдыннан орлыкларны агуларга, яровойлаштырырга һәм чылатырга.

3. Авык бәрәңгесе үстерү өчен бәрәңге кисентеләре җыю эшен көчәйтергә, бу эшкә пионерларны һәм мәктәп балаларын тартырга. Әзерләнгән чәчүлек материалның тулысынча саклануын тәэмин итәргә.

КЫР ЭШЛӘРЕНӘ ҖАНЛЫ ТАРТУ КӨЧЕН ӘЗЕРЛӘҮ ТУРЫНДА

Атларны игътибар һәм мәхәббәт белән тәрбияләүне, дөрес ашатуны тәэмин итәргә, һәрбер атның иң якын араларда ук уртача һәм уртачадан югары көрлектә булуына ирешергә.

Моның өчен:

1. Колхоз правлениеләре белән берлектә, ветеринария врачы яки зоотехник катнашы белән, колхозлардагы барлык атларны карап чыгарга, авыру һәм хәлсез атларны аерым группаларга куярга, аларны тәрбияләүне яхшыртырга һәм тиешенчә дәвалауны оештырырга.

Пионерлар һәм мәктәп балалары атларны шефлыкка алып, аларны көн саен тәрбияләп торуны һәм күзәтеп торуны тәэмин итәргә тиешләр.

2. Яшьләрдән контроль постлары төзеп, аларга атларга азыкның тулысынча бирелүен, язга калдырылган терлек азыгы запасларының ничек саклануын көн саен, көндез дә, төнлә дә тикшереп торуны тапшырырга. Тикшерү вакытында күренгән кимчелекләр турында шунда ук колхоз правлениесенә хәбәр итәргә һәм аларның бетерелүенә ирешергә.

3. Ат карауычылык эшенә иң яхшы яшьләрне куярга. Яшьләр көче белән щеткалар һәм кыргычлар әзерләргә, атларны чиста тотарга.

4. Атларның иясезләндерелүен бетерүгә, аларны колхозчыларга нык итеп беркетүгә, сбруйларның һәм повозкаларның яхшы хәлдә булуына ирешергә.

5. Эштә тарту көче итеп аз продукт бирә торган сыерлардан, һәм бигрәк тә кысыр сыерлардан яки үгезләрдән, киң күләмдә файдаланырга.

Чәчү башланганчыга кадәр һәрбер колхозда кирәк кадәр җигү әйберләре әзерләп куярга, сыерларны җигеп эшләргә өйрәтергә.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮНЕ ҮТКӘРҮ БУЕНЧА

1. Намуслы хезмәт үрнәге күрсәтергә, кырларда киң җәелеп стахановча эшләргә, иң яхшы сабанчылар, чәчүчеләр, орлык ташучылар булырга.

Колхоз һәм совхоз кырлары стахановчылары хәрәкәтен киңәйтергә, яшь колхозчыларның көненә икешәр һәм аннан да күбрәк норма үтәүләренә ирешергә.

2. Хезмәтне төгәл оештыруга, колхозчылар арасында хезмәт дисциплинасын тагын да ныгытуга ирешергә. Чәчү вакытында эшне кояш чыгу белән башларга һәм караңгы төшкәч тәмам итәргә.

3. Кечкенә балалары булган хатыннарның кырда эшләүләрен җиңеләйтү өчен колхозларда балалар ясләләре, площадкалар төзүдә һәм аларның яхшы эшләүләрен тәэмин итүдә инициатива күрсәтергә.

4. Комсомолец тракторчылар һәм тракторчы хатын-кызлар кыр эшләрендә машиналардан тулысынча файдалану үрнәге күрсәтергә тиешләр.

Комсомолец яки комсомолка эшли торган трактор эшсез тормаска яки эш нормасын үтәми калмаска тиеш.

Трактор бригадаларына техник яктан яхшырак хезмәт күрсәтү өчен комсомолецлар атка җигелгән күчмә мастерскойлар төзү эшенә керешергә тиешләр.

5. Ягулык һәм майлау материалларына бик нык экономия ясау өчен кискен көрәш алып барырга. Ягулыкка экономия ясау буенча һәрбер МТС та һәм совхозда комсомолецлардан һәм яшьләрдән контроль постлары төзергә. Планда күрсәтелгән тракторларны газогенераторлы ягулыкка күчерүдә актив катнашырга, газогенераторлы тракторларда эшләүгә комсомолецлар һәм яшьләр арасыннан иң яхшы тракторчыларны тәкъдим итәргә. Бу тракторлар өчен колхозчы яшьләр көче белән шакмаклар хәзерләүне оештырырга.

6. Тракторларга ягу өчен эшләнмәгән скипидар, дегет, шулай ук көпчәк мае хәзерләүдә өлкәнең колхозларына һәм совхозларына практик ярдәм күрсәтергә.

Комсомолецлар һәм комсомолкалар! Яшь колхозчылар һәм колхозчы кызлар, МТС һәм совхоз эшчеләре!

Язгы чәчүне үткәрүдә кыенлыклар аз булмас. Партия оешмалары җитәкчелегендә, барлык колхозчыларны туплап һәм чәчүне уңышлы үткәрү өчен көрәшкә берләштереп, без уңышка ирешербез һәм җиңеп чыгарбыз. Моның шулай булачагын безнең бөек ватаныбызга мәхәббәтебез, немец басып алучыларга нәфрәтебез, героик Кызыл Армиягә бөтен көч белән булышлык итәргә әзер торуыбыз раслый.

Комсомолецлар һәм комсомолкалар! Колхозларның, бригадаларның, звеноларның социалистик ярышын киңрәк оештырыгыз, аңа барлык яшьләрне, барлык колхозчыларны тартыгыз! Язгы чәчүне тиз һәм югары сыйфатлы итеп үткәрүне чын оештыручылар булыгыз! Чәчүне бик яхшы итеп үткәрү өчен көрәштә үз сафларыгызны оешу ягыннан тагын да ныгытуга ирешегез, яшьләр белән элемтәгезне киңәйтегез һәм ныгытыгыз, аларның иң яхшы өлешен комсомол сафларына тартыгыз.

Без, бу хатта әйтелгән йөкләмәләрне өстебезгә алу белән ВЛКСМ Үзәк Комитеты байрагы өчен көрәшкә кушылабыз һәм Горький өлкәсе комсомолецларын һәм яшьләрен социалистик ярышка чакырабыз.

Комсомолец һәм комсомолка иптәшләр! Колхоз, совхоз һәм МТС яшьләре! Безнең алдыбызда зур, мактаулы, ләкин кыен бурычлар тора. Аларны уңышлы рәвештә башкарып чыгу өчен безнең бөтен мөмкинлекләребез бар.

Колхозчы яшьләр,—югары иген уңышы өчен сугышчан походка!

Язгы чәчүне вакытында һәм югары сыйфатлы итеп үткәрик!

Дошманны тар-мар итүдә, туган җиребезне немец-фашист пычраклардан азат итүдә батыр Кызыл Армиябезгә булышыйк!

Большевиклар партиясе, туган юлбашчыбыз һәм полководецыбыз Иосиф Виссарионович **Сталин** җитәкчелегендә җиңүгә таба, алга!

ОБОРОНА ТҮГӘРӘКЛӘРЕ

Саба районының «Байкал» колхозындагы тулы булмаган урта мәктәп янында оборона түгәрәкләре төзелгән иде. Укучылардан 62 кеше ПВХО түгәрәкләрендә укып зачет тапшырды. 22 укучы һәм 39 колхозчы ГСО значегына норма тапшырдылар. Хәзерге көндә РОКК түгәрәгендә 22 кеше укый. Алар 1 нче мартка укуны тәмам итәчәкләр. Бу түгәрәккә җитәкчелек итүче иптәш Золотова «Байкал» колхозында һәм тирә-яктагы башка колхозларда санитария-гигиена темаларына әледән-әле лекцияләр үткәреп килә.

АГИТАТОРЛАРГА ЯРДӘМГӘ

ХӘРӘКӘТЧӘН ҺӘМ КОНКРЕТ АГИТАЦИЯ ӨЧЕН

Большевистик агитациянең көче — аның хәрәкәтчән булуында. Безгә шундый агитация кирәк ки, ул практик эш белән бәйләнгән булсын һәм конкрет нәтиҗәләргә китерсен. Практик тормыш белән бәйләнмәгән, формаль төстә оештырылган агитация файдасыз һәм ул эштә ярдәм итә алмый. Агитатор, әгәр дә ул алдына куелган максатка ирешергә теләсә, үзенең беседаларын предприятиенең, совхозның һәм колхозның эшендә булган җитешсезлекләрне читләтеп үтәргә тиеш түгел.

Агитатор, партия тарафыннан куелган төп лозунгтан чыгып, хәзерге көндә алда торган бурычларны аңлатырга, аны үтәүгә массаны тупларга тиеш.

Бөек ватан сугышы барган шартларда тылдагы агитаторның төп бурычы — дисциплинаны ныгытудан, массаны ватан алдында торган бурычны үтәүгә, фронтка, Кызыл Армиягә ярдәм итүгә туплаудан гыйбарәт.

Безнең байтак агитаторлар үзләренең эшләрен чыннан да соклانырлык итеп оештырдылар. Партком секретаре урынбасары иптәш Козлов булган Н-че завод агитаторларының эше аеруча күренекле булып тора. Агитатор иптәш Военушкин, көндезге аш вакытында, мастер Шемякин группасында беседа үткәрә. Аның беседалары бик җанлы була. Иң элек ул, Совет Информбюросы белдерүләрен укый.

— Менә күрәсезме иптәшләр, Кызыл Армия дошманга көннән-көн каты ударлар ясый. Кызыл Армиянең уңышларга ирешүендә сезнең хезмәтегезнең дә катнашы зур бит, —ди ул.

Сүзен дәвам итеп:

— Декабрь ае планын күпмегә үтәдегез?

— 166 процентка,—дип җавап бирәләр эшчеләр.

— Димәк, сез фронтка планнан тыш 60 проценттан артык продукция бирдегез. Һәрбер артык деталь дошманга өстәмә удар дигән сүз. Шулай иптәшләр, һәрберегез планны арттырып үтәүгә ирешергә тиешлесез.

Аннан соң мастер иптәш Шемякин сүз ала. Ул:—минем группада планны үтәү генә түгел, аны арттырып үтәү өчен дә бөтен мөмкинлекләр бар,—ди. Ул мөмкинлекләрне практик мисалларда санап чыга.

Аның артыннан Максимов һәм Салиев иптәшләр чыгып:—Без икешәр норма үтәргә йөкләмә алабыз,—дип белдерәләр. Башка эшчеләр дә бу фикергә кушылганлыкларын аңлаталар. Беседа соңында бу группа членнарының барысы да Кызыл Армиянең 25 еллыгына икейөзпроцентчылар сафына басарга, хезмәт җитештерүчәнлеген 34 процентка күтәрергә йөкләмә алдылар һәм мастер Арбузов группасын ярышка чакырдылар.

Икенче көнне агитатор иптәш Военушкин беседа вакытында элекке көнне алган йөкләмәләрнең үтәлешен тикшерде. Нәтиҗәдә, бу группаның заданиене 243 процентка үтәгәнлеге беленде. Шул ук көнне цехта мастер иптәш Шемякин группасының гүзәл уңышларын яктырткан «Молния» чыкты. Күп тә үтмәде, бу группаның инициативасы белән башланган уңышлар бөтен цех коллективын чолгап алды.

Агитатор иптәш Военушкинның гади, хәрәкәтчән һәм конкрет беседаларының гүзәл нәтиҗәләре әнә шундый.

Телдән агитациянең төрле формалары һәм методлары бар. Аларның иң таралган формасы булып докладлар, җыелышларда, митингларда агитаторларның чыгышлары, групповой һәм аерым рәвештә үткәрелгән беседалар, күмәк рәвештә газеталар, китаплар кычкырып уку һәм башкалар тора.

Агитация яхшы нәтиҗә бирсен өчен, агитатор үзенең аудиториясен, һәрбер тыңлаучысын яхшы белергә, аның нәрсә белән кызыксынуын өйрәнергә тиеш. Бу хәл беседада куелган бурычларның уңышлы үтәлүенә, массаны фронтка ярдәм итүгә туплауга мөмкинлек бирә.

Беседаларны нәрсәдән башлап җибәрү мәсьәләсе дә бик әһәмиятле. Беседаны ике төрле башлап җибәрергә мөмкин. Кайбер агитаторлар беседаны гомуми положениеләрдән башлап, аннан соң гына конкрет мәсьәләләрне аңлаталар. Ә кайберләре киресенчә, конкрет мәсьәләләрне аңлатканнан соң гына гомуми положениеләрдән чыгып йомгак ясыйлар. Бу методларның икесе дә яраклы, әлбәттә.

Һәрбер агитатор беседаларга яхшылап әзерләнергә тиеш. Бу әзерлек тема эчендәге материалларны яхшылап өйрәнүдән, беседага план төзүдән, урындагы конкрет, кызыклы материалларны туплаудан гыйбарәт. Беседаларның планы зур булмаска, практик тормыш белән нык бәйләнгән булырга тиеш.

Агитатор булу—җаваплы һәм мактаулы эш. Шуңа күрә, партия тарафыннан тапшырылган бу эшкә зур игътибар белән карарга, үзенә йөкләтелгән бурычны намус белән үтәргә кирәк. Агитатор үзенең эшен шулай оештырырга тиеш ки, аның һәрбер сүзе массаны дошманга каршы көрәшкә туплаучы булып яңгырасын.

А. КУЗНЕЦОВ, М. НАЗАРОВ.

КАРТА ЯНЫНДА

Безнең алдыбызда бай һәм киң илебезнең картасы. Ул, гадәттә булганча, кәгазьгә төшерелгән карта түгел. Зур тактага, төрле ачык буяулар белән зурайтылып эшләнгән карта. Анда Совет иленең зур шәһәрләрен, тимер юлларын һәм бай елгаларны күрәсең.

Менә фронт полосасы. Нинди киң һәм катлаулы бит ул. Аны газеталарда укып кына хәтердә җицел калдырып булмый. Ә менә картаны карагач, аны бик тиз төшенәсең. Кызыл Армиянең уңышларын, аның дошманга бер-бер артлы ясаган ударларының гүзәл нәтиҗәләрен — халык яши торган пунктларны, шәһәрләрне алуын күрәсең.

Героик сугышчыларыбызның алган шәһәрләре биредә Кызыл флаг белән күрсәтелгән.

Бу карта янында һәркөнне йөзләрчә эшчеләр булалар. Дистәләрчә агитаторлар эшчеләргә фронт хәлләрен, коллектив алдында торган бурычларны аңлаталар. Бердәм коллектив бу чакыруга практик эш белән, фронт заказларын срогыннан алда үтәү белән җавап бирә.

Партия оешмасы секретаре иптәш Горохов булган Н-че заводның ишек алдында оештырылган күргәзмә агитациянең нәтиҗәләре уңышлы һәм зур.

Р. ӘХМЕТШИНА.

КАЗАН ТИМЕР ЮЛЫНДА ВАХТАГА БАСТЫЛАР

Казан тимер юлы коллективы Кызыл Армиянең 25 еллыгы исемендәге вахтага басты.

Юдино депосы паровозчылары Зуев һәм Шәрәпов иптәшләр вахтаның инициаторлары булдылар. Алар поездларны югары тизлектә йөртүне, ягулыкка экономия ясауны кагыйдә итеп алдылар.

Алдынгыларның сүзләре эштән аерылмый. 5 нче февральдә машинист иптәш Шәрәпов, мөһим йөк төялгән поездны Вятские Поляныдан Юдиного китергәндә, техник тизлек нормасын сәгатенә 12 километрга арттырып үтәде. Бу, поездларны кривоносча йөртүнең гүзәл үрнәге, ул кышкы кыенлыкларны җиңә белүне күрсәтә.

Октябрьның 25 еллыгы исемендәге паровозлар колоннасының житәкчесе иптәш Зуев соңгы рейсларның берсендә техник тизлек нормасын сәгатенә 5 километрга арттырып үтәде.

— Фронтта һөҗүм бара. Тыл да аннан калышмаска тиеш,—ди кривоносчы машинист.

Яшь машинист иптәш Ремизюк шушы көннәрдә поездны, расписаниедә күрсәтелгән вакытка караганда, 2 сәгать 10 минутка элек китерде. Орденлы машинист иптәш Вырин поездлар хәрәкәте графигын 3 сәгать 32 минутка элек үтәде.

Бу патриотлар, Кызыл Армиянең һөҗүм операцияләрен тәэмин итү өчен, гаскәрләр, сугыш припаслары, кораллар һәм азык төялгән эшелоннарның фронтка өзлексез китеп торырга тиешлеген яхшы аңлыйлар. Моны аңлаган барлык тимер юлчылар шулай эшләргә тиешләр.

МАШИНИСТ БАКИЕВНЫҢ УҢЫШЛЫ РЕЙСЫ

Әгерҗе депосы машинисты Закир Бакиевның һәм диспетчер Петрунькинның инициативасы буенча, бүлектә поездлар хәрәкәтен тизләтү өчен ярыш җәелдерелде.

Иптәш Бакиев беренче булып, хәрби йөк төялгән поездны су һәм ягулык алу өчен юлда туктамыйча, Әгерҗедән Вятские Поляныга алып барды. Диспетчер белән ярышып, ул составны Вятские Полянында расписаниедә күрсәтелгәнгә караганда 4 сәгатькә элек кабул итте.

Бу хәрәкәткә кушылган машинист Ступак, машинист ярдәмчесе Закиров һәм кочегар Жежель поездны шулай ук кривоносча темп белән алып бардылар. Участок расписаниедә күрсәтелгәнгә караганда 5 сәгать 45 минутка элек үтелде. Техник тизлек нормасы сәгатенә 12 километрга арттырып үтәлде.

Машинист Ралдугин да иптәш Петрунькин белән ярышка чыкты. Иптәш Петрунькин поездны юлда туктаусыз алып баруны тәкъдим итте. Шуның нәтиҗәсендә иптәш Ралдугин техник тизлек нормасын сәгатенә 10 километрдан да артыгракка үтәде.

Стахановчыларның гүзәл рекордлары

Ленинград тимер юлчылары белән ярышка чыккач, Юдино депосының механика цехы эшчеләре продукция эшләп чыгаруны арттыруга, локомотивларга ремонт ясауны тизләтүгә юнәлдерелгән стахановчы хезмәтнең яңа формасын эзләп таптылар.

Смена башланыр алдыннан алдынгы эшчеләр мастер тарафыннан тапшырылган заданиене билгеле бер санда үзләре арттыралар. Аерым детальләрне тизрәк эшләү буенча үзара договор төзиләр.

Шушы көннәрдә мастер, токарь иптәш Чижовка поршень штокларын үткәрләргә наряд бирде һәм бу эшне 3 сәгать эчендә башкарырга тәкъдим итте. Ә стахановчы Чижов поршень штокларын 25 минут эчендә үткерләп бетерде.

Токарь иптәш Маркушин крейцкопфны 8 сәгать эчендә үткерләргә задание алган иде. Ул бу эшне 2 ярым сәгать эчендә тәгәлләде. Токарь иптәш Просвирин тендер скатларын 8 сәгать урынына, 6 сәгать эчендә үткерләде.

РАЙОН ПРЕДПРИЯТИЕЛӘРЕНДӘ

Чистайлылар алдынгылык өчен көрәшәләр

Чистайдагы предприятиеләр һәм артельләр Кызыл Армиянең 25 еллыгын производствода яңа уңышларга ирешү, халыкка киң куллану товарлары җитештерү планын арттырып үтәү белән каршылау өчен Казан шәһәренең предприятиеләрен һәм артельләрен социалистик ярышка чакырганнар иде. Чистайлылар бу ярышта өстен чыгу өчен нык көрәш алып баралар. Бу көрәш гүзәл нәтиҗәләр бирә: Мәсәлән, мебель фабрикасы (директоры иптәш Розенблюм), январь аенда киң куллану товарлары эшләп чыгару планын 281,9 процентка үтәде. Агач кыру цехында эшләүче стахановчы иптәш Грутман айлык планны 210 процентка, Толдикина 185 процентка, столяр Краснер 300 процента үтәделәр.

Галантерия фабрикасы (директоры иптәш Брезенов) январь планын 167,9 процентка үтәп чыкты. Уенчыклар ясау цехы планны 300 процент итеп үтәде. Бу цехта эшләүчеләрдән Небаева норма үтәлешен 200, Ромма 230 процентка җиткерделәр.

Промкомбинат (директоры иптәш Баринов) январь ае планын 163 процентка, кун заводы (директоры иптәш Балыкин) 132 процентка, трикотаж фабрикасы (директоры иптәш Новиков) 139 процентка, «Красная звезда» заводы 135 процентка, «Путь» артеле 130 процентка, Лесзаг коллективы киң куллану товарлары эшләп чыгару планын 150 процентка үтәде.

Ворошилов исемендәге артель коллективы (председателе иптәш Веденеев) 1 нче квартал планын Кызыл Армиянең 25 еллыгы көненә 200 процентка үтәргә йөкләмә алган иде. Артель членнары сүзләрендә нык торалар. Ярышта өстен чыгу өчен бөтен мөмкинлекләрдән файдаланалар. Бу артель январь ае планын 342 процентка үтәп чыкты. Аркан ишү цехы январь ае планын 5.100 процентка, кап сугу цехы—192, тегү цехы—250, уенчыклар цехы 138 процентка үтәделәр. Бу артель членнары Миронов, Евдокимова, Нуретдинова һәм Макаров иптәшләр көн саен 2—3 норма биреп эшлиләр. Иптәш Бараксин планын 350 процентка үтәп бара.

Ш. ШАКИРОВ.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

18 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

18 нче февральдә **Орел** өлкәсендә безнең гаскәрләр район үзәге һәм тимер юл станциясе Залегощьны, халык яши торган зур пунктлардан **Покровскоены һәм Верхняя Сосканы** алдылар.

Ростов-Доннан көнбатыштарак безнең гаскәрләр, һөҗүмне җәелдерүне дәвам иттереп, халык яши торган күп кенә пунктларны, шул исәптән район үзәге **Матвеев Курганны** алдылар.

Краснодар районында безнең гаскәрләр район үзәге һәм тимер юл станциясе **Северскаяны**, халык яши торган зур пунктлардан **Старовеличковскаяны, Смоленскаяны, Азовскаяны** алдылар.

Фронтның башка участокларында безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

* * *

17 нче февральдә безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында дошманның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 100 дән артык автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 20 артиллерия батареясының утын бастырдылар, 2 сугыш припаслары складын шартлаттылар, бер батальонга якын пехотасын таркаттылар һәм бер өлешен юк иттеләр.

* * *

Новошахтинскидан көнбатыштарак безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган 60 пунктны алдылар. Дошман авыр югалтуларга дучар ителде. Безнең механикалаштырылган бер берләшмәбез генә дә 1.000 нән артык немец солдатларын һәм офицерларын юк итте һәм 1.500 кешене плен алды. Немецлар, безнең гаскәрләрнең алга баруын тоткарларга маташып, ашыгыч рәвештә яңа частьлар һәм берләшмәләр оештыралар. Безнең гаскәрләр немецларның 79 нчы пехота дивизиясен зур югалтуларга дучар иттеләр. Бу дивизия, күбесенчә, лазаретлардан вакытыз җитмичә чыгарылган яраланган солдатлардан һәм офицерлардан, шулай ук Таганрог һәм башка аэродромнар командалары солдатларыннан төзелгән иде.

* * *

Ворошиловградтан көньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләр уңышлы рәвештә алга бардылар һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Н-че берләшмә частьлары дошманга каршы бик каты сугышларда аның 10 танкысын һәм 2 бронемашинасын зарарладылар һәм яндырдылар. 37 автомашина, 7 миномет һәм башка трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Краматорская районында безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Бер участокта совет подразделениеләре алга киттеләр һәм 400 гә якын немец солдатларын һәм офицерларын кырдылар. Икенче бер участокта дошман пехотасының һәм танкларының контратакасы кире кайтарылды. Славянск шәһәрендә безнең сугышчылар 2 ягулык склады, бер кием склады, бер сугыш припаслары складын һәм күп төрле сугыш милекләре кулга төшерделәр.

* * *

Курскидан төньяктарак безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар. Н-че берләшмәнең хәрәкәтчән группасы дошман тылына барып чыгып 15-20 километр алга китте һәм халык яши торган берничә пунктны алды. Икенче бер участокта Н-че часть сугышларның ике көне эчендә 500 гә якын немец салдатларын һәм офицерларын юк итте һәм 30 кешене плен алды. Трофейлар кулга төшерелде. Шулар арасында 18 орудие, 50 пулемет, 400 винтовка һәм автоматлар, 2 танкетка, 34 автомашина һәм бер радиостанция бар.

* * *

Карел-Фин ССР ның бер районында хәрәкәт итүче Тойво Антикайнен исемендәге һәм Чапаев исемендәге партизан отрядлары кинәт акфиннар гарнизонына һөҗүм иткәннәр. Партизаннар, часовойларны үтереп, халык яши торган пунктка тавышсыз гына барып кергәннәр. Сугыш нәтиҗәсендә дошман гарнизоны тар-мар ителгән. Совет патриотлары 100 дән артык дошман солдатларын һәм офицерларын кырганнар, дошманның 2 пушкасын, еракка ата торган бер орудиесен юк иткәннәр, 2 сугыш припаслары складын шартлатканнар һәм бер азык складын яндырганнар.

* * *

Немецларның 44 нче пехота дивизиясенең плен алынган командиры генерал-лейтенант Дюбуа болай диде: «Мин 131 нче пехота полкының команда пунктында подполковник Вальтер һәм башка офицерлар белән берлектә плен алындым. Сталинград өчен сугыш артык озакка сузылды һәм безнең резервларыбыз җитмәде. Без, руслар кыш көне һөҗүм итәрләр дип уйлаган идек. Билгеле, немецларның иң көчле армияләреннән берсен Кызыл Армиянең чолгап алачагын һәм җимерәчәген бер кем дә уйламаган иде. 6 нчы армиянең тар-мар ителүе һәм юк ителүе—ул зур фаҗига. Үткән елны, Москва янында немец гаскәрләре чигенгәннән соң, безнең рухыбыз шулай ук бик төшенке булган иде. Сталинград янындагы җиңелү, ул аннан да авыррак удар булды һәм ул сугыш хәрәкәтләренең барышына тәэсир итәчәк. Мин 44 нче дивизияне кабул иткән чакта анда 17.000 ләп кеше бар иде. Мин эшли башлаганнан бирле 4 тапкыр шактый күп өстәмә көчләр килде. Чолганып алыныр алдыннан дивизиядә 13.000 гә якын кеше калган иде. Алар барысы да я сугышларда һәлак булдылар, яки плен алындылар».

Кызыл Армиянең 16 нчы февральдә

* * *

Харьков шәһәрен алуы турындагы хәбәр бөтен дөньяга таралды һәм җир шарының иң ерак почмакларына кадәр барып җитте. Бу хәбәрне дөньяда радиостанцияләрнең күпчелеге тапшырды. Аны барлык илләрдәге газеталар диярлек басып чыгардылар. Тик немецлар командованиесе генә әле совет гаскәрләренең Харьковны алулары турында хәбәр иткәне юк. Гитлерчы күз буяучылар гуяки әле һаман да Харьков янында бара торган сугышлар турында әкиятләр уйлап чыгаруларында дәвам итәләр. Мәсәлән, 18 нче февральгә каршы төндә Германиянең информация бюросы болай дип хәбәр итте: «Харьковта бик каты урам сугышлары хәзердә дә дәвам итә. Шәһәрнең күп өлеше ут эчендә. Шулай ук шәһәрнең башка өлешләре дә һәр ике як өчен бөтенләй үтә алмаслык...». Гитлерчыларның бу хәбәре баштан аяк ялган. Хәзер азат ителгән Харьковта бернинди дә сугышлар юк. Һөҗүм итеп баручы Кызыл Армия частьлары Харьковтан үтеп киттеләр һәм алга таба баралар.

Башларын югалткан гитлерчылар дөреслекне әйтергә кыймыйлар. Алар, әле соңгы ударлардан айнып җитмәгән немец халкын аптыраштa калдырудан куркалар һәм аны Харьковнын китүе турындагы фикергә астыртын гына хәзерләргә телиләр. Менә шуңа күрә дә Берлинга «үтәргә мөмкин булмаслык урамнар» турында һәм гүяки Харьковта дәвам итә торган урам сугышлары турында әкиятләр уйлап чыгарырга кирәк булган.

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ СУГЫШЧАН УДАРЛАРЫНЫҢ ҖИМЕРГЕЧ КӨЧЕ АРТА БАРА

Совет гаскәрләренең җиңүләре турында Англия матбугаты

ЛОНДОН, 16 февраль. (ТАСС). Англиянең барлык матбугаты совет гаскәрләренең җиңүләренә зур игътибар бирүне дәвам иттерә. «Дейли экспресс» газетасының хәрби күзәтүчесе болай дип яза: «Кызыл Армиянең Ростовны алуы гаять дәрәҗәдә зур мораль һәм материаль әһәмияткә ия булып тора. Ростовның алынуы русларның шундый тулы тактик өстенлеккә ирешүләрен күрсәтә ки, хәзер руслар тарафыннан үзгәрешсез уңышлы итеп тормышка ашырыла торган хәрәкәтләрне дошманга хәзер нинди дә булса пунктны, хәтта көчле итеп ныгытылган һәм бик каты оборонада саклана торган пунктларны да, кулда тотып калуга исәп тоту кыен».

Газета, совет гаскәрләренең өч ай диярлек һөҗүм итүләре нәтиҗәсендә Германия армиясе шундый югалтуларга дучар булды ки, мондый югалтуларны әле сугышлар тарихы белми», дип яза.

«Ньюс кроникль» газетасының хәрби күзәтүчесе шулай ук Германия армиясенең гаять зур югалтуларына туктала.

«Алты ай вакыт эчендә,—дип яза күзәтүче,—Германия командованиесе Дон бассейнына гаять зур күләмдә кораллар, сугыш припаслары һәм хәрәкәт составлары җибәрде. Боларның барысын да немецлар алты көн эчендә кире чыгарып бетерә алмадылар».

«Спектейтор» журналы болай дип яза: «Ударлар шул кадәр тиз ясала һәм аларның уңышлылыгы шул кадәр ачык ки, бары тик сокланырга гына кала. Курск һәм Белгородны немецлар бер ел буена кулларында тоттылар. Бу пунктларда аларның позицияләре алынмаслык дип уйларга мөмкин иде. Ләкин бу ныгытылган шәһәрләрне совет гаскәрләре искиткеч тиз алдылар».

«Санди экспресс» газетасы болай дип яза: «Россиянең сталинчыл даһилыгы хәзер гитлерчы армияләрне артка алып ташлый. Кызыл Армия Донбасска киң һәм тирән үтеп керде һәм ул Сталинград янында булганга караганда да көчлерәк һәм куркынычлырак чолгау хәрәкәте белән дошманга куркыныч тудыра. Безнең союзникларыбыз үзләренең гүзәл хәрәкәтләре белән шуңа ирешteләр ки, берничә көн генә әле моннан элек тә бу мөмкин булмаслык булып күренгән иде».

Англия информация министрлыгы үзенең бүгенге хәрби күзәтүендә, Ростовны алуның гаять зур әһәмияте бар, чөнки ул совет гаскәрләренең Кавказны уңышлы азат итүләренең йомгаклану аккорды булып тора һәм Кызыл Армиягә тагын да зуррак яңа уңышларга ирешүгә мөмкинлек бирә, дип белдерә.

«Экономист» журналы, Англия һәм АКШ үзләренең гаять зур ресурсларының бөтен көчен мөмкин кадәр тизрәк дошманга каршы ташларга тиешләр, дип күрсәтә. «Хәзер,—дип яза журнал,—союзниклар өчен куркыныч кирәгеннән артык сак булудан һәм сугыштан аерылгысыз булган тәвәккәллеккә каршы кирәгеннән артык саклanудан гыйбарәт. Тиз һәм җиңүле һөҗүм вакыты килеп җитте».

«Йоркшир пост» газетасы да шулай ук кичекмәстән хәрәкәт итәргә чакыра. Газета болай диде: «Англиягә һәм Америкага немецларның җиңелүен көчәйтүгә һәм аларны яңа фронтларда операцияләр алып барырга мәҗбүр итүгә әзер булу вакыты килеп җитте!».

ҚЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ ХАРЬКОВНЫ АЗАТ ИТҮЕ ТУРЫНДА ИДЕН

ЛОНДОН, 17 февраль. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Англиянең түбәнге палатасы рус гаскәрләренең Харьковны алуларын кайнар рәвештә котлаган. Чит Ил Эшләре министры Иден палата утырышында, бөтен палата рус армиясен бу җиңү белән котларга тели, дип белдергән.

ЧИТ ИЛ ХРОНИКАСЫ

—Төньяк Африка кампаниясенең беренче өч ае эчендә союзниклар авиациясе күчәр державаларының 607 самолетын юк иткән. Шул ук вакыт эчендә союзниклар үзләре 250 машина югалтканнар.

—Республикачы сенатор Остин һәм вәкилләр палатасы члены республикачы Уэльсворт хәрби производство һәм хуҗалыкның башка әһәмиятле тармакларында ирләр һәм хатын-кызлар өчен хезмәт йөкләмәсе кертү ягыннан АКШ президентына хокук бирү турында конгресска закон проекты тәкъдим иткәннәр. Закон проекты 18 дән 65 яшькә кадәр булган ирләр өчен һәм 18 дән 50 яшькә кадәр булган хатын-кызлар өчен хезмәт йөкләмәсе кертүне күздә тота.

—Канадада халык санын алуның рәсми йомгаклары игълан ителгән. Бу саннарга караганда, хәзер Канадада 11.506.655 кеше тора.

—Төньяк Африка халкы өчен союзниклар 45 мең тонна төрле продуктлар һәм товарлар төяп озатканнар. Аларның бер өлеше инде илтеп тапшырылган, бер өлеше юлда.

КАРАЛМАГАН ГАРИЗАЛАР, БЮРОКРАТ ҖИТӘКЧЕЛӘР ТУРЫНДА

Чепья район советы башкарма комитетының «Иртәгә тикшерергә» дип исемләнгән папкасында дистәләрчә гаризалар күп вакытлардан бирле тикшерүне көтеп яталар.

Менә Сталин исемендәге колхоз члены иптәш Әхмәтҗанова гаризасы. Ул үткән ел 250 хезмәт көне эшләгән. Ә колхозчыларның гомуми җыелышы аны «эшкә чыкмаган өчен» дип колхоздан чыгара. Иптәш Әхмәтҗанова колхозга кире кайтаруны сорап район советы башкарма комитетына гариза бирә. Бу гаризаның район советы башкарма комитетына килеп керүенә 3 ай вакыт узып киткән. Ләкин ул әле дә булса каралмаган.

«Крестьянская газета» колхоз члены фронтовик Камал Зыятдинов район советы башкарма комитетына хат яза. Хатта болай диелгән: «Минем семьямда авыру хатыным һәм 4 балам калды. Семьямны ягулык белән тәэмин итүне һәм мөмкин булган башка нәрсәләр белән ярдәм итүегезне сорыйм». Район советы башкрама комитеты председателе иптәш Кәримов бу хатны ачып укыган һәм аның почмагына «район җир бүлеге мөдиренә» дип резолюция салган. Ләкин, кызганычка каршы, эш шуның белән беткән. Бу хат буенча нинди чара күрелүе турында беркем дә, бернәрсә дә белми.

Үткән ел язгы чәчү вакытында Киров исемендәге колхозның 350 гектар җир мәйданына «Бакча», «Уңыш», «Яңа юл» колхозлары чәчәләр. Киров исемендәге колхоз председателе иптәш Шәймәрдәнов бу җир мәйданына төшкән дәүләт йөкләмәләрен шушы колхозлардан түләтүне сорап, район советы башкарма комитетына гариза бирә. Анда бу гаризаның өстенә «уполнаркомзаг иптәш Вафинга бирергә» дигән резолюция салына. Ә гариза әле шушы көнгә кадәр Вафинга җибәрелүне көтеп папкада ята бирә.

Район советы башкарма комитетында хезмәт итүчеләренең жалобаларына бюрократларча карашның гафу ителмәслек дәрәҗәгә җитүен тагын бик күп төрле фактлар белән китерергә мөмкин.

Менә тагын бер факт. «Заря» колхозы председателе Яковлев район советы башкарма комитетына колхоз өчен тимерче табуда ярдәм итүне сорап гариза бирә. Район советы башкарма комитеты председателе аның бу гаризасын, ни өчендер, район финанс бүлеге мөдире Гарифҗановка җибәрә. Ә Гарифҗанов: «Мин тимерчеләр белән эш итмим, акчалар белән эш итәм»—дип резолюция сала да, гаризаны язучыга җавап бирүне артык эш дип санап, аның гаризасын архивка ыргыта.

Чепья район советы башкарма комитеты җитәкчеләренең хезмәт ияләре тарафыннан бирелгән жалобаларга карата мондый бюрократларча карашларына чик куярга һәм бу эштә гаеплеләргә чара күрергә вакыт.

Ф. ГАЛИЕВА.

Җаваплы редактор **И. ҮЗБЕКОВ.**

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор, редактор урынбасары— АТС 76—29, секретарь, промышленность, транспорт һәм авыл хуҗалыгы бүлеге— АТС 79—29. типография 36—60.

II Р543 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» нәшриятельствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 273